КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 28 август г.Казань № 721

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәгълүмат технологияләре өлкәсендәге кече эшмәкәрлек субъектларын бизнес-инкубацияләү» дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2014 ел, 26 май, 352 нче карары белән расланган «Мәгълүмат технологияләре өлкәсендәге кече эшмәкәрлек субъектларын бизнес-инкубацияләү» дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәгълүмат технологияләре өлкәсендәге кече эшмәкәрлек субъектларын бизнес-инкубацияләү» дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2014 ел, 26 май, 352 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 27 октябрь, 788 нче; 2014 ел, 29 декабрь, 1055 нче, 2015 ел, 1 апрель, 203 нче; 2015 ел, 10 октябрь, 758 нче; 2017 ел, 25 гыйнвар, 25 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Мәгълүмат технологияләре өлкәсендәге кече эшмәкәрлек субъектларын бизнес-инкубацияләү» дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктның уникенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында конкуренцияне үстерүгә булышлык күрсәтү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр күрсәтү базарлары исемлеген һәм 2016 – 2018 елларга Татарстан Республикасында

конкуренцияне үстерүгә булышлык күрсәтү буенча чаралар планын («юл картасы») раслау турында» 2016 елның 26 декабрендәге 776 нчы боерыгы;»;

2.1 пунктның унбишенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

4.5.14 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.5.14. Резидент проектын техник тормышка ашыруны тикшерү, иң яхшы техник карарны эзләү, эшләнә торган җайланманың тест үрнәген эшләү һәм проектны тормышка ашыру белән бәйле бүтән эшләрне эшләү максатларында махсуслашкан җиһазлардан (3D-принтер, смартфоннар белән тест эшлә стенды һәм бүтән кирәкле җиһазлар белән) файдалану мөмкинлеге бирү (техник мөмкинлекләр булганда һәм бизнесинкубацияләү хезмәтләрен күрсәтүгә норматив чыгымнар нигезендә бүленгән акча исәбеннән).»;

5.9 пункт үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин